■ Исламда балалар

# Ризаэддин Фәхреддин нәсихәтләре

### МӘКТӘП

Чәй эчкәннән соң, киемнәрегезне киеп укырга барыгыз, чыгып китәр алдыннан ата вә аналарыгызның кулларын үбеп, ризалыкларын алыгыз, туганнарыгыз белән күрешеп:

“Аллаһы Тәгалә юлына чыктым, Аллаһы Тәгалә миңа тәүфыйкъ бирсә иде”, - дип, нечкә күңел вә ихлас белән мәктәп юлына чыгыгыз.

Мәктәп юлында уйнамагыз, гаҗәп нәрсәләргә тамаша итеп тормагыз, очраган балалар белән сөйләшеп юанмагыз, тәрбиясез балалар вә бозык адәмнәр белән бергә йөрмәгез, урамда уйнамагыз. Чөнки бу нәрсәләр сәбәбеннән вакытыгыз әрәм булыр. Үзегез да сизмичә холкыгыз бозылыр, бәлки олы адәмнәр кебек үзегезне тота белеп йөрегез. Мәктәптән кайтканда да вә башка җирләргә йөргән вакытыгызда да шулай уйлагыз!

Мәктәпкә кергәч, аяк киемнәрегезне, бүрек, тун кебек өс киемнәрегезне билгеле җиргә куеп укытучы вә башка иптәшләрегезгә ачык йөз белән сәлам бирегез вә алар белән дәрес укырга башлагыз!

Дәрес башланыр вакыт җитсә, һичкемне тыгызламыйча вә рәнҗетмичә, әдәп белән генә урыннарыгызга урнашыгыз, әгәр дә урыннарыгыз тыгыз булса, көчләмичә-төртешмичә бәлки: “Шулай итә күрсәгез лә!” - дип, иптәшләрегездән иркенлек сорагыз!

Үзегез дә, һичбер тарафка авышмыйча, бәлки туп-туры вә укытучыга карап, иптәшләрегез белән бер тигез булып, як-якка карамыйча, борылмыйча, шатланып утырыгыз, мәктәпкә кереп-чыгып йөргәндә дә инсафлы булыгыз!

Мәктәп эчендә булган тавышларга катнашмагыз, уйнаучы вә тәрбиясез балалар белән иптәш булмагыз, алар белән бер җирдә утырмагыз, үзегез билгеләнгән урыннан рөхсәтсез күчмәгез!

Бертөрле дәрес бирелгәндә, сез икенче дәресләргә карамагыз бәлки укытучы тарафыннан бирелгән дәрескә тәмам күңелләрегезне җибәрмәгез, бу сәбәптән осталарыгыздан ризалык алырсыз, гомерегездә файда күрерсез.

Укытучы сүз сораган вакытта аяк өстенә торып, кулларыгызны күкрәкләрегезгә куеп, хөрмәт белән укытучыга карап торыгыз, соравын яхшы аңлагыз, соңыннан белгәнегез белән ачык вә яхшы тавыш белән җавап бирегез, иптәшләрегездән сораган сүзләргә катышмагыз!

Сүзегездә яки язуларыгызда булган ялгышларыгызны укытучылар төзәтсәләр, моның өчен күңелсезләнмәгез, чөнки укытучылар сезне яраталар вә сездә булган ялгышларны бетерергә тырышалар.

Укытучыларыгыз укырга, язарга, ятларга кушкан эшләрнең барысын да яратып җиренә җиткерегез.

Кечкенә вакытта чисталык вә тәртипкә хөрмәт белән карый торган булу - баланың гакыллы вә алдан күрүчән булачагына олуг бер билгедер. Шуның өчен киемнәрегез чиста һәм билгеле бер урында, китап вә язу әйберләрегез тәртипле булсын. Бармакларыгыз вә дәрес әсбапларыгыз карага буялып йөрмәсен!

Каләмнәрегезне киемнәрегезгә яки чәчләрегезгә сөртмәгез, авызыгызга кабып йөрмәгез, бу нәрсәләр авыруга вә пычрак йөрүгә сәбәп булыр. Бәлки каләм сөртер өчен, яныгызда аерым бер киндер чүпрәк кисәге булсын!

Кулыгыз карага яки башка нәрсәгә буяла, тиз генә юып чистартыгыз, киемнәрегез исә һәрвакыт чиста булсын!

Мәктәп вә башка җирләрнең бүрәнә вә стеналарына, асып куелган хариталарга (карталарга) яки китапларга, урамда йөргәндә койма вә капкаларга, бакчаларда булган эскәмияләргә язмагыз. Бу нәрсәләр исә - тәрбиясез балалар эшедер.

Туп вә даганда атыну кебек уеннар сеңерләрне куәтләндерер, тырышлыкны уяндырыр, тәнне сәламәтләндерер. Шуның өчен моның кебек уеннардан мәрхүм булмагыз!

Уеннарыгыз буш вакытта, дәресләрегезгә вә башка эшләрегезгә кимчелек китермәслек итеп һәм чиста урыннарда, яхшы һавалы җирләрдә, бик әдәпле булсын!

Мәктәптән кайткач, ата вә аналарыгызга сәлам биреп, китапларыгызны вә дәрес әйберләрен билгеле урынга куегыз! Уйныйсыгыз килсә, әдәп белән генә уйнагыз, дәресләрегезне әзерләмичә йокламагыз!

Кирәк - мәктәп эчендә, кирәк - башка җирдә, әдәпсез сүз сөйләшмәгез, тиешсез ишарәләрдә булмагыз, чөнки мондый әйберләрдән тәрбияле адәмнәр нәфрәт итәр.

Дәресләрне калдырып яки билгеле сәгатьләреннән кичегеп йөргән шәкертләр өчен сабаклар кыен булыр. Иптәшләреннән түбән дәрәҗәдә калыр, шуның өчен дәресләрегезне дәвам итегез, сәгатьләреннән соңга калмагыз!

Мәктәпкә йөрүдән вә сабак укудан максат - Иман белү, тәрбияле вә камил адәм булу кирәклеген хәтерегездән чыгармагыз һәм шушы максатка ихлас белән йөрегез. “Ни өчен мәктәпкә барасыз вә ни өчен укыйсыз?” - дип сораучы булса, сез дә: “Аллаһы Тәгаләнең боерыгын җиренә җиткерү өчен, атам-анама догачы булу вә туган һәм кардәшләремә, кабиләдәшләремә вә диндәшләремә бер файдалы кеше булуны өмет итәм”, - дип җавап бирегез. Бу рәвештә җавап бирү баланың гакыллы булачагына дәил булыр.

Мәктәпләрдә дәресләрнең тәмамлануы соңында “Инде уку вакыты үтте, гыйлемем да җитәрлек булды” дип, гыйлемнән вә китаплардан аерылмагыз, бәлки буш вакытларыгызда һаман китапларыгызны укыгыз вә һәрбер яңа китапларны, әдәби китапларны укыгыз. Бу сәбәпле зиһенегез ачылыр, гакылыгыз артыр, фикерегез тугры булыр.

### ГЫЙЛЕМ

Гыйлем күңел күзен ачар, наданлык - караңгылыкны бетерер. Олы дәрәҗәләргә тоташтырыр, дошманнарга каршы корал булыр. Тереклекне саклар. Дөнья көтү сәбәпләрен белдерер, йорт эчендә вә гомумхалыклар белән ни рәвештә булырга кирәклеген өйрәтер. Гыйлем - галимнәрнең зиннәте, адәмнәрнең хөрмәте булып, каракрдан куркусыз дәүләт вә һич бетми торган байлыктыр.

■ Илхам

# Рухы күңелләрдә яши



Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Мөселманнарыбызның яраткан гәзите “Рисаләт” укучыларын дин әһелләребез белән таныштыруны дәвам итәбез. Талантлы, тынгысыз шагыйрәбез Әлфирә Саттарова - Бикмәтова Туймазы шәһәрендә яши һәм иҗат итә. Ул үзенең газиз әтисе Мөсәгыйт Саттаровның (1885-1965) шигырьләрен, мөнәҗәтләрен, вәгазьләрен бергә туплап, “Исмам жигачы” дип аталган китабын чыгарды.

- Әткәй Коръәнне су эчкәндәй укый, сүзен-сүзгә тәржемә итеп, безгә аңлата иде. Ул безне шәригать тәртипләре белән таныштырып үстерде. Әткәй биш вакыт намазын һичтә калдырмады. Матур итеп, азан әйтеп башлар иде, - ди шагыйрә.

Мөсәгыйт Саттаровның әтисе Гайнетдин Саттаров Мулла авылында туып-үсеп, тирә-якта дан тоткан биктә укымышлы мулла булган. Шул дәвердә ул Хажга барган. Укымышлы гаиләдә туган Мөсагыйт Саттаров яшли дини белем, тәрбия алган, биктә тырыш, сабыр егет булган. Ул Бәйрәкә мәдрәсәсендә укып, соңыннан үзе дә шунда белем бирә. Артабан “Галия” мәдрәсәсендә эшен дауам итә. Шул ук вакытта Мөсагыйт алты яшьтән сукыр калган агасына Коръән ятлаткан. Агасы Коръән Хәфиз булып гомеренең соңгы көненә кадәр Мулла авылында иң хөрмәтле кеше булып яшәгән.

- Әтием олы йөрәкле сәсән иде ул. Якташларына дини тәрбия бирү теләге белән ул бик күп дини шигырлар язып калдырды. Үзе исән чакта ук аларны кулдан кулга йөртеп, күчереп алучылар күп булды, - тип исли кызы Әлфирә. Кызганычка каршы, матбугатка җибәргән әсәрләре, дини темага язылган булу сәбәпле, совет чорында басылмаган. Бу талантлы сәсәнгә әлеге көннәрне күрергә насыйп булмаган, куанычыннан очып йөрер иде. Ислам динен ихлас хөрмәт иткән, аның калдырган васыяты: мөнәҗәтләре, вәгазьләре, дини шигырьләрен тәкдим итәбез.

### Без - Мөхәммәт өммәте

*Хак Тәгалә хәзрәтенең чиксез зурдыр кодрәте,*
*Барчабызга белү кирәк: без - Мөхәммәт өммәте.*
*Соңгы заман кавемнәре динне тотмый башлады,*
*Ата-баба йолаларын себереп түгеп ташлады.*
*Күп галимнең исеме белән аңлатмыйлар, белмәссең,*
*Исеме Габдулла булса да, кальбе кяфер, сизмәссең.*
*Безнең милләт кәвемендә зур хата бар, ялгыш юл,*
*Габдулла булса - мөселман, Иван булса - кяфер ул,*
*Итәгатьсез, гыйбадәтсез Габдулласы, Иваны,*
*Юк аларның аермасы, юк аларның Иманы.*
*Иван белән Габдулланың аермасы бер генә -*
*Гөсел, гыйбадәт, пакъ тәһарәт, Аллага зекер генә.*
*Ошбу гамәлне кылмаган Габдулласы, Иваны,*
*Икесе дә бер үк төсле, алданма син, бел аны.*
*Савап эзләп мәҗлес җыйсаң, Коръән-хәтем кылдырсаң,*
*Аңласана, утта янар, гамәлсезне чакырсаң.*
*Синең мәҗлес гамәлсезгә - тик бер сафа, ашханә,*
*Әкият сөйли, тутыра карын, оялмый, түргә менә.*
*Изге мәҗлес шул була - кайда изге сүз генә,*
*Коръән сүзе, изге вәгазь сөйләүче дә бер генә.*
*Изге мәҗлес күләмендә гел әкият диңгезе,*
*Кем өйләнгән, кем өй салган, кемнең симез үгезе.*
*Булмый икән изге мәҗлес, ялган мәҗлес кормагыз,*
*Тәгам, хөрмәт исраф итеп, мордарлар чакырмагыз!*
*Ул хөрмәтнең бәһасына күпләп акча тотсагыз,*
*Барып дәрвиш йортларына, дога-хәтем кылсагыз,*
*Гарип бәндә, балаларга, сәдакалар бирсәгез,*
*Йөз мәртәбә савабы зур, изге юлда булсагыз.*
*Әһле Ислам бармы монда, шуны уйлап карагыз,*
*Кяферләрдән гыйбрәт алсак, бик аз кала арагыз.*
*Йә Ходаем, сиңа мәгълүм, бетеп бара динебез,*
*Барлык мөселман кайгыда, инде ниләр күрербез,*
*Яхшы, изге китапларны яндырдылар, калмады,*
*Мәсҗед, мәдрәсә, мулланың тар-мар килде даннары.*
*Тәһарәт, гыйбадәт кылабыз тик өлгергән чагында,*
*И Ходаем, ни кылаем, без синең кочагында.*
*Кальбебез сиңа мәгълүм, сиңа сәҗдә кылабыз,*
*Сиңа гына иман китереп, Салават әйтеп торабыз.*
*Хак Тәгалә хәзрәтенең чиксез зурдыр кодрәте,*
*Барчабызга белү кирәк, без - Мөхәммәт өммәте.*

# Ислам дине, буҙа беҙҙе коткарҙы

**Зөбәйҙә ҠӘЛӘМОВА,**
**Учалы районы, Сораман ауылы**

Ейәнсура районына Урал батыр бәйгеһенә йыйылғанбыҙ. Күңелле сығыштарҙан алған яңынан-яңы тәьсораттар менән көндәрҙең үткәне лә һиҙелмәй. Ә кистәрен уҡытыусылар йәнә ҡорға йыйыла. Бер-берең менән аралашып, һөйләшеүҙән үҙеңә дәрт-көс алғандай тояһың. Яҡшы хәбәрҙәр һөйөндөрә, ә ямандары иһә ғибрәт алырлыҡ. Стәрлетамаҡ ҡалаһы мәктәптәренең береһенән килгән уҡытыусы менән ултырҙаш булырға яҙғайны миңә лә. Әңгәмәләшеү төрлө темаға арнала: дини тәрбиә, милли эсемлектәрҙең шифаһы хаҡында ла һүҙ сыҡҡас, улы менән булған ҡот осҡос хәлде бер тынала бәйән итте.

- Улымдың тәненә уралған имәнес ҙур йыланды имеш, һәнәк ярҙамында сәнскеләйем. Ырым-фәләндәргә ышанмаһам да, командировканан бығаса булмағанса, йөрәкһеп ҡайтып индем. Фәрештәләр ысынбарлыҡтағы хәлде аңғартҡан булған икән шул: берҙән-бер улым, минең өсөн ғәзиз кешем, наркоманға әйләнгән. (тәүбә!)

Минең өсөн донъя емерелгәндәй тойолдо. Дуҫ-иштәр, табиптар, таныш-тоноштарҙың кәңәштәре бер ҡолаҡтан инеп, икенсеһенән сыкты. Мине тотошлайы менән күңел төшөнкөлөгө ялмап алды. Үҙемде ҡайҙа ҡуйырға белмәй, йәнем-тәнем өҙгөләнгәндә, мейемдә өмөт саткыһы яралды. Бәлки, мәсеткә, барып, Хоҙайға ялбарып ҡарарғалыр? Тәүәкәлләнем. Дежурҙа ултырған муллаға эсте бушаткас, бер аҙ еңеләйеү тойғоһон кисерҙем. Дин әһеленең кәңәштәренә таянып, төрлө сүрәләрҙе өйрәнергә тотондом. Буҙа менән дауалау мөмкинлеген дә мулла әйткәйне. Күрше подъезда йәшәгән әбейҙән буҙа ҡойоу серҙәренә төшөндөм һәм улымды ошо шифалы эсемлек ярҙамында даулау эшенә керештем. Әҙәм балаһын тормош һуҡмағында осраған ҡаршылыҡтар һынай, ти. Әлхәмдүлилләһе шөкөр. Динебеҙ, шифалы эсемлек арҡаһында аҡ үлемдән баламды йолоп ҡала алдым, - тине ул.